**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Большеменгерского сельского поселения**

422756, Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

422756, Атнинский муниципальный район
с.Большой Менгер, ул. Советская, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 05» ноябрь 2024 ел. № 5

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2024 елның 15 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 15 ноябрь 2024 ел 18.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны — Иске Мәңгәр авылы, Тукай урамы, 11 йорт, Иске Мәңгәр авыл клубы;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 8 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Иске Мәңгәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Иске Мәңгәр торак пункты халкына массакүләм мәгълумат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә,

көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Мәңгәр авылы клубы бинасын төзекләндерү (грим бүлмәсен ремонтлау һәм материаллар сатып алу));
2. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру));"
3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Мәңгәр авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау).

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә түбәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Иске Мәңгәр авылы, Тукай урамы, 11 йорт буенча мәгълумат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Филатова